**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

---

**2021 елның 21апреле** **15 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегендәге Кече Кабан авылы торак пунктында яңа формалаштырыла торган урамнарга исем бирү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең ” Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары , 2021 елның 8 апрелендәге топонимика буенча район комиссиясе бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең Кече Кабан авылы торак пунктында яңа формалаштырыла торган урамнарга түбәндәге атамаларны бирергә:

улица Габдуллы Тукая – Габдулла Тукай урамы;
улица 100 лет ТАССР – ТАССР нын 100 еллыгы урамы;
улица Мусы Джалиля – Муса Җәлил урамы.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

3. Карар имзаланган көннән үз көченә керә.

**Башлык –ТР**
**Лаеш муниципаль районы**
**Олы Кабан авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Р.Ш.Илһамов**